ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 ноябрь 2021 ел № 7188

Башкарма комитетның 2021 елның 26 мартындагы 2088 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Мниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү буенча комиссиянең 2021 елның 21 октябрендәге 8 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2021 елның 26 мартындагы 2088 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 1 июлендәге 4400 номерлы, 2021 елның 15 октябрендәге 6814 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына, аңа кушымтада каралганча пунктлар өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев

Башкарма комитетның
2021 елның 1 ноябрендәге
7188 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Объектның тибы | Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының махсуслашуы | Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны координаталары | Объекттан файдалану |
|---|---|---|---|---|---|
| Автозавод районы | | | | | |
| 10.1 | Ипподром шугалагы районы | Киоск (18 кв.м) | Кулинария продукциясе сату | 472360.15 2325063.36<br>472361.59 2325061.97<br>472365.07 2325065.55<br>472363.64 2325066.95 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| 10.2 | «Медео» шугалагы районы | Киоск (10 кв.м) | Кулинария продукциясе сату | 472780.64 2323434.05<br>472782.73 2323436.20<br>472787.03 2323432.02<br>472784.93 2323429.87 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |
| Үзәк районы | | | | | |
| 12.1 | Азатлык мәйданы шугалак районында | Киоск (12 кв.м) | Кулинария продукциясе сату | 470392.33 2323257.49<br>470398.11 2323259.10<br>470397.64 2323261.01<br>470391.82 2323259.42 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 12.2 | «Мәйдан» мәйданы | Кисок<br>(9 кв.м) | Кулинария продукциясе сату | 471456.30 2321568.61<br>471454.98 2321571.30<br>471457.67 2321572.62<br>471458.99 2321569.93 | Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева